**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АТАБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422635 Лаишевский район, с. Атабаево
Ул.Молодежная ,д. 1,
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

**АТАБАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422635 Лаеш районы, Атабай авылы
Яшьлэр урамы , 1нче йорт
тел, факс: 8(84378)-4-87-41
E-mail Atab.La@tatar.ru

2021елның « 12 » августы 13 номер

## КАРАР

**Атабай авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урынын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган, яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә кулланылучы һәм тиешле җыймау, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру аркасында гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү калдыклары белән эш итү Кагыйдәләре нигезендә, Атабай авыл җирлеге Уставына, Атабай авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә таянып, КАРАР ИТӘМ**:**

1. Атабай авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучыларга (милекчеләре, яллаучылар, күпфатирлы йортлардагы биналардан файдаланучылар булган һәм әлеге биналарның милекчеләре төзегән күпфатирлы йортлар белән идарә итү килешүе яки мондый йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару килешүе булган терекөмешле лампаларны кулланучылардан тыш)– беренчел җыю һәм урнаштыру урыны Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Атабай авылы адресы буенча урнашкан «Атабай агрофирмасы» ҖЧҖ (2 нче склад) территориясендә билгеләргә.

2. Юридик затларга (оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә) һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итүче индивидуаль эшмәкәрләргә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затларга (оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә) мондый йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр башкару шартнамәсе нигезендә,күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләре, яллаучылары, аннан файдаланучылар булган терекөмешле лампаларны кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыруны, кагыйдәләр нигезендә, тәэмин итәргә.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган Кагыйдәләр нигезендә терекөмеш лампалар кулланучы юридик затларга (оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә) һәм индивидуаль эшкуарларга тәкъдим итәргә:

- эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыю, туплау, алардан файдалану, зарарсызландыру, күчереп йөртү һәм урнаштыру буенча инструкцияләр эшләргә һәм күрсәтелгән калдыклар белән эш иткән өчен җаваплы затларны билгеләргә;

- куркынычлылыгы I-IV класслы калдыкларны зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеген тормышка ашыруга лицензиясе булган, эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыю, куллану, йогышсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру белән шөгыльләнүче юридик затлар яки шәхси эшмәкәрләр белән эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыю турында шартнамә төзергә.

4. « Атабай авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмеш лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урынын билгеләү турында» Атабай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2014 елның 8 апрелендәге 8 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга .

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы , Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Атабай авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Атабай авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р.Хәлилова**